**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУАШ БОРНАЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 13 апреле** **7№**

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы «Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау хакында» 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елдагы «Оборона турында» 61-ФЗ номерлы, 1997 елдагы «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизацияләү турында» 31-ФЗ номерлы, 1998 елдагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53-ФЗ номерлы, 2003 елдагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 719 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 6 февралендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 103 номерлы карары, Җирлек Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Чуаш Борнае авыл җирлеге» территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта «(3 айдан артык вакытка)» сүзләреннән соң «шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлгәннәре дә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Чуаш Борнае авыл җирлеге»
Башкарма комитет җитәкчесе: И. Г. Зарипов